# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
## Татар Шуган  авыл җирлеге Советы

Татар Шуган авылы № 147 «23» сентябрь 2019 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татар Шуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Татар Шуган  авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Татар Шуган авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум кулэмендэ, 2 торкем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 150 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган  түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татар Шуган авылында  Совет, Х.Такташ, Яна урамнарнын юлларына щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)
- Татар Шуган  авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Татар Шуган авылында җәй көне территорияне чабу;
- Татар Шуган авылында коры агачларны, куакларны кисү;
- Татар Шуган авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Татар Шуган авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен ремонтлау (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү);
-Татар Шуганы авылында «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;

- Татар Шуган авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясау һәм урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Татар Шуган авылы, Совет урамы, 41в йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рэис Г.З.Мияссарова